КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 апрель г.Казань № 304

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 28 март, 193 нче, 2019 ел, 20 декабрь, 1174 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибендә:

2.1 пунктның «к» пунктчасында:

икенче абзацта «(эшкә сәләтсез гражданнарны карауны гамәлгә ашыручы эшкә яраклы булмаган затларга компенсация түләүләреннән тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«айлык социаль пособие рәвешендә дәүләт социаль ярдәме турындагы законнар нигезендә бирелә торган дәүләт социаль ярдәме;

18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына

айлык пособие;

айлык акчалата түләү (шул исәптән пенсионерларга да);

18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләрдә, шул исәптән тәрбиягә бала алган гаиләләрдә укучыларга транспортта йөрү өчен айлык субсидия;

18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләрдән, шул исәптән тәрбиягә бала алган гаиләләрдән алты яшькә кадәрге бала өчен дару чаралары сатып алу өчен субсидия;

бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие;

чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие;

өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү.»;

3.1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бер тапкыр бирелә торган түләү һәм натураль ярдәм рәвешендә дәүләт социаль ярдәме турында законнар нигезендә күрсәтелә торган дәүләт социаль ярдәме;»;

җиденче, унынчы – уникенче, уналтынчы абзацларын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 803 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 27 декабрь, 1207 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү тәртибендә:

1 пунктның беренче абзацында «18 яшькә кадәрге» сүзләреннән соң «һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәти тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган гаиләләрнең мөлкәти тәэмин ителеше дәрәҗәсе» сүзләрен өстәргә»;

4 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән балага айлык пособие исәбеннән» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Узган чорларда түләнгән айлык пособиеләрнең суммасы айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең керемнәре составында исәпкә алынмый.»;

8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән документларның бердәнбер ата-анасына кереме булмаган очракта гына булмавы, йә аның кереме булмаган очракта һәм башка ата-ана хезмәт эшчәнлеген башкара, йә пенсионер, йә хезмәт эшчәнлегенә сәләтен чикли торган инвалид, йә билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган очракта, бер кешегә йә аның кереме булмаган очракта

яисә башка ата-анасының хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган, йә инвалид булып торган очракта айлык пособие билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.»;

12 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гаиләдә инвалид булган ата-аналарның яки инвалид балалар булган балаларның булмавы.»

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин